СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1-25 от 02 октября 2017г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Ишки авыл җирлеге башкарма комитетының "Референдум уздыру инициативасы турында" 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 6 нчы номерлы карары, Ишки авыл җирлеге Советының "Референдум уздыру инициативасы турында" 2017 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 3-24 нче номерлы карары, Ишки авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре" 2014 нче елның 2 нче апрелендә кабул ителгән 2-30 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2017 нче елның 19 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол

хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. **Дорожная деятельность в отношении автомобильных дорог местного значения в границах населенных пунктов поселения**:

-Ишки торак пунктында туфрак белән капланган юлларны ремонтлау, Мәктәп урамы 150 м; Яшьләр урамы 150 м.

2. Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:

Васильево торак пунктында су скважинасы әйлэндереп алу

« ӘЙЕ » « ЮК »

4. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы И.Т.Степановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге башлыгы
вазыйфасын башкаручы,
Совет председателе /И.Т.Степанов/

СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ